| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«21» ноября 2023г. № 179

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 18 июлендәге 109 номерлы «Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 18 июлендәге 109 номерлы «Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

А) түбәндәге эчтәлекле 2.3.5 пункт белән тулыландырыга:

«2.3.5. Хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү очраклары һәм тәртибе каралмаган.»;

Б) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре.»;

В) 2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - 17 эш көненнән артмый.

Мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 2 өлешендә каралган документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - документлар органга тапшырылган көннән алып 32 көннән дә соңга калмыйча.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы документлар органга тапшырылган көннән исәпләнә башлый.»;

Г) 2.6.1 пунктының1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхесне таныклаучы документ (мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә шәхесне таныклый торган башка документны Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясындагы 18 өлешендә каралган мәгълүмати технологияләрне кулланып кабул итү барышында гамәлгә ашырылырга мөмкин).

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин